
Марафончы Нил Гатин



Н. Гатин. 1970 г.

«Хезмәт резервлары» стадионы. Авыл болыныдай зур яшел мәйдан. Аның әйләнәсендә киң такыр юл. Ак сызыклар аны сукмакларга бүлгән. Бүген монда, 1957 елда, Татарстан беренчелегенә җиңел атлетика ярышлары бара. Җыелган халык бигрәк тә йөгерешчеләрне кararга ярата. Мин дә йөгерәм. Хәзер 5 000 метрга старт биреләчәк. Утызлап кеше, аяк яздырып, тегендә-монда йөгергәли. Күбесе таныш. Яңалары да бар. Әнә теге, ак тәнле, базык гәүдәле егет, әледән-әле «Спартак» тренеры Кашаев янына килеп туктый. Нидер сөйләшкәләп, минем якка да караштырып алалар. Мөгаен, бу Иван Сергеевичның яңа шәкертедер. Исәпкә алырга кирәк. Куркырлык йөгерешчеләр башка күренми. Бардыр, бәлки... Пединститутка җитез яшьләр килгәндер. Тик, хәрәкәтләре белән, тән төзелешләре, үз-үзен тотышлары белән күзгә ташланырлык, өлгергән йөгерешчеләргә охшаганнары күренми. Ә бу егеттә нидер бар! Сизелә. Дөрес, гәүдәсе авыррак күренә. Аяклары бик таза һәм юан. Аларны бик югары күтәрмичә генә, ничектер кырыйданрак, үзенчә алдыра. Басынкы кыюлык, тәвәккәллек тә яшеренгән бугай егеттә. Сак булырга кирәк!

Карап торганда йөгерешчеләр күп кебек булса да, асылда беренче урын өчен көрәш, күп очракта, ике-өч кеше арасында гына бара. Башкалары, үзенә күрә, ярыш фоны — декорация булып кына кала. Дөрес, аларның да үз исәпләре бар. Кайсы дустын яисә танышын узарга омтыла, кайсы бүгенгә үз көчен сынап, киләчәктә көчлерәкләр арасына керү юлларын билгели.

Старт! Башладык. Алга чыгам. Югыйсә, яшьләрнең үз чамаларын белмичә ыргым ясап юлны бикләве ихтимал. Аларны әйләнеп узгалаганчы, кемнеңдер аерылып китүе мөмкин. Аннары, ку син аның артыннан! Унике ярым әйләнеш — күп булса да, тигез көндәш туры килсә, һәр адымың санаулы.

Әһә, дөрес уйлаганмын. Әлеге шыртый чәчле егет артка төшкән. Тигез генә бара. Үзен әлләни сиздерми. Борылышларда күз кырыем белән генә карап алам. Башкалар кала бара. Бу — ябыштырып куйган кебек. Тизләнеше ничек икән? Бераз кызулап карыйм әле. Калмый — нык тора. Тагын бер сынап карыйм! Юк, бирешми. Без моны «үткән идек инде» — КАИдагы курсташым Михаил Лашкин белән тарткалашканда, артыбыздан шыпырт кына барган пединститут студенты Виктор Тогулев, соңгы йөз метрда алга ыргылып, икебез-

не дә финиш ясарга өйрәткән иде. Кашаев моны күреп торган иде. Ярый, тагын бер тапкыр тартып карыйм. Дөрес! Көндәшемнең нияте ачык. Инде үзе алдан йөгереп карасын. Артка калганнар ерак. Куып җитү ихтималлары юк. Бу тизләнештән соң акрынайтам. Егет алга чыга. Оһо! Әле көче — бер олау. Трактор кебек тарта. Үзең төшеп калма! Йөгерәсе дә күп калмады. Дүрт-биш әйләнеш кенә. Шулай барырга кирәк. Тизлеге бик зур түгелдер. Финиш ыргымын сагалап барырга! Бик иртә кузгалып китмәсен. Үзем соңрак һәм кискенрәк башлармын. Бу хәтле таза гәүдә белән бик тиз кузгала алмас. Әмма, бер кузгалып китсә, моны тотармын димә.

— Алга чык! Егетне ял иттер! — дип кычкыргалый башладылар. Бигрәк тә, заманында минем белән ярышып, үзләре «зыян күргән» хәзерге яшь тренерлар тырыша. Үзләреннән булмаганны бу егеттән күрәселәре килә. Ашыкмагыз әле, вакыты җиткәч чыгармын. Соңгы йөз метр. Егет үз хәлен аңлаган иде инде. Зур каршылык күрсәтмәде.

— Икенче урында — авыл хуҗалыгы институты студенты Нил Гатин, — дип хәбәр иттеләр. Пединституттан да түгел, университет яисә химиктан да түгел. Авыл хуҗалыгыннан! Күптән булганы юк. Бу — яңалык иде. Республикада — икенче урын! Ни дә булса торырлык яшь йөгерешче өчен. Өметле егет бу — Гатин! Икенче очрашуда аны, болай гына — җиңел, алып булмастыр.

Нил Гатин көндәлегеннән:

«Татарстан беренчелегенә ярышлар «Хезмәт резервлары» стадионында булырга тиеш. Ул матур, җайлы урында урнашкан. Янында Казанның Үзәк паркы, бик яшел. Бу районда һава да чиста. Ярышта катнашучы стайерлар саны бик күп. Аларның берсен дә белмим. Күнегүләрне авылда һәм уку хуҗалыгында ясадым. Кәефләр бик яхшыдан түгел, борчылам. Күбесенең кигән костюмнары да бик яхшы. Болар көчле йөгерешчеләрдер инде. Старт! Утызга якын егет, узыш атлары кебек, алга ыргылды. Бер-берсен этүләр дә булды, чак кына егылмадым. Алда биш кеше йөгерәбез. Җиде әйләнеш ясагач, тренерлар: «Акрын йөгерәсез!» — дип кычкыра башлады. Беркем дә алга чыкмый, берсен-берсе саклыйлар. Алга чыгып, тизрәк йөгерә башладым. Соңгы әйләнеш. Финишка 50 метр калгач, ябык кына берсе узды.

Тәҗрибәле йөгерешче Камил Мохтаров беренче, мин — икенче. 5 000 метрны 16 минут 12 секундта йөгереп, үземнең рекордымны 23 секундка яхшырттым».

Әлегәчә 5 000 м дистанциягә йөгерүдә Татарстан рекодчылары исемлегендә өч кенә фамилия тора иде: Фадеев Г. — 17 минут 2 секунд (1934 ел); Костромин — 15.53 (1950 ел); Мотыйгуллин М. — 15.30 (1953 ел).

Баксаң, Гатинның шәхси нәтиҗәсе Мотыйгуллин куйган Татарстан рекордыннан бик ерак та түгел икән. Ярыштан-ярышка секундларны шундый аерма белән киметә башласа, бу — 42 секундлы араны үтәргә аңа күп вакыт та кирәкмәстер кебек. Тик рекорд бер урында гына тормас шул. Рекордлар тарихы минем күз алдымда язылды.

Нилга килгәндә, ул институтта укый башлагач кына спорт белән танышкан икән. Аңа хәтле — аның балачагы, яшьлек еллары — элек Бүләр районына кергән Колбай-Мораса авылында узган.

— Укуда бик тырышырга туры килде, — ди Нил. — Беренче семестрны уңышлы гына тәмамладым. 1956 елның февралендә институт беренчелегенә 300 метрга йөгерү ярышы уздырылды. Бик дулкынландым. Стартта, куркак куянныкы кебек, аякларым калтырады. Старт! Башка катнашучылар бик тиз йөгереп китте. 100 метр гына йөгерәләр, диярсең. Хурлыкка калам икән дигән уй башыма килде. 200 метр билгесенә җиткәндә беренче булып йөгерүче белән тигезләндем, 50 метр калгач алга чыктым. Мин — беренче! Институт чемпионы булдым.

Икенче курста укый башлагач Нил беренче тапкыр 5 000 метрга йөгереп карый. Нәтиҗәсе — 18 минут 35 секунд. Шуннан аның бу дистанциядә рекордлар аулавы башлана. Бер ел вакыт үткәч, 1957 елның августында Татарстанның «Спартак» командасы Нальчикка бара. Анда өч көн рәттән өч йөгерештә катнаша. Беренче көнне 1 500 метрны 4 минут 25 секундта үтә. Икенче көн — 5 000 метр — 16.35. Өченче көн — 10 000 метр — 34.36. 1958 елның сен-

тябрендә Нил Гатин 5 000 метрга йөгерүдә Татарстан чемпионы исемен ала. Вакыты — 15 минут 33 секунд.

Шул ук — 1958 елны Нил Гатин биш чакрымга уздырылган кросс йөгерешендә дә Татарстан чемпионы булды.

Бер ай эчендә — икенче кат җиңү! Нил Гатин — Татарстанның ике тапкыр Чемпионы! Шатлан, Мораса!

Нил Гатин көндәлегеннән: 1959 ел. Смоленск. Россиянең «Спартак» беренчелеге. 5 000 метр. Стартта 27 кеше. Беренче адымнан ук кискен көрәш башланды. Тугыз әйләнештән соң алда бишәү йөгерәбез. Бөтен көчемә артка калмаска тырышам. Әлегә мин — бишенче. Соңгы әйләнештә бар көчемә китәм. 100 метр калганда, мин — икенче. 1960 елда 5 000 метрны 15 минут 16 секундта, 1961 елда — 15.12 йөгерәм. Бу елларны 10 000 метрга йөгерүдә берничә рекорд куям.

1961 елның июнендә Горький шәһәрендә Россиянең Идел буе зонасы ярышларында катнаштым. 10 000 метрга йөгерү графигы төзедем. Аны күргән иптәшләрем үтәлешенә шик белдерде: «Бу эсседә шул тизлек белән йөгерсәң, чыдый алмыйсың, йөгерүне ташлыйсың», — диләр. Үземчә йөгерергә булдым — график буенча башладым. Максатым — үзем өчен рекорд кую иде. Һәр әйләнешне бер чамада, тигез тизлек белән үтәргә тырышам. Чыннан да, июнь эссесенә түзәргә бик авыр булды. 400 метрга 25 тапкыр әйләнергә кирәк бит. Түздем, ярыштан чыкмадым. Фиништан соң әкрен генә йөгереп ял итәм. Стадион радиосыннан хәбәр итәләр: «Татарстан командасыннан Нил Гатин 10 000 метрга йөгерүдә яңа рекорд куйды — 32 минут 8 секунд». 1961 ел — Нилның рекордлар уңышы җыю елы булды. Ул Татарстан рекордын 10 000 метрлы йөгерештә биш тапкыр яңартты.

Бу елның ахыргы ярышы — сигез чакрымга Татарстан кроссы Нил Гатин җиңүе белән тәмамлана: 8 чакрым — 24 минут 15 секунд.

1962 ел. Татарстанның өченче җәйге Спартакиадасы. 5 000 метрга йөгереш — 1. Нил Гатин — Спартакиада чемпионы. Вакыты — 15 минут 7,8 секунд. 10 000 метрга йөгереш: Нил Гатин, тагын бер кат, — Спартакиада чемпионы. Вакыты — 31 минут 20 секунд — Татарстанның яңа рекорды.

1963 ел. Татарстан чемпионаты. Казан, Үзәк стадион. 5 000 метр: 1 — Нил Гатин вакыты — 15 минут 2,6 секунд; 10 000 метр: 1 — 31 минут 35,6 секунд. Россиянең «Динамо» чемпионаты, Краснодар. 10 000 метрга йөгереш: Нил Гатинның вакыты — 31 минут 18 секунд — Татарстанның яңа рекорды.

1964 ел. Татарстан чемпионаты. Нил Гатин — ике тапкыр чемпион: 5 000 метр — 15 минут 8,8 секунд; 10 000 метр — 31 минут 37,4 секунд. РСФСР чемпионаты. Ульяновск. 10 000 метрга йөгереш: Нил Гатин— 31 минут 15,2 секунд — Татарстанның яңа рекорды.

1965 ел. Нил Гатин — өч тапкыр Татарстан чемпионы: 5 000 м — 15.02. 10 000 метр — 31.40. Кросс 8 чакрым



Татарстан чемпионаты. 1958 ел. Беренче — Н. Гатин.

— 24.34.

1966 ел. Нил Гатинга марафон йөгерәсе генә калды: беренче тапкыр асфальт юлда ул 1963 елда Казанның Ленин районы Сабантуенда йөгергән иде. 15 чакрымны 46 минут 15 секундта үтеп, беренчегә дигән бүләкне алган иде. Быел Ленинградта Россиянең «Динамо» җәмгыяте беренчелегендә — 20 чакрым йөгерешендә — өченче булды. Вакыты — 1 сәгать 3 минут 17 секунд.

Кайсы йөгерешченең генә «Марафончы» буласы килми икән?! Сүзне Нил Гатинның үзенә бирик: «Камил Мохтаров. — Марафон йөгерергә теләгең юкмы? — дип сорады. — Йөгереп карармын, — дидем. Грозный шәһәренә Россия марафонына киттек. Шәһәрнең яңа төзелгән, бәлки бу ярыш өчен махсус, кунак өенә урнаштырдылар. Хәтта ярыш көнен дә башка шәһәрләрдәге гадәт буенча гына түгел (ял көннәрендә — якшәмбедә була иде), сишәмбе көнне уздырырга булганнар. — «Без марафон йөгерешен бөтен кеше күрсен, ул — зур бәйрәм булсын, дип хәзерләндек, — диде Чечен-Ингуш Республикасы спорт комитеты вәкиле. Чыннан да, без йөгергән көнне Грозный шәһәре Казанның иң зур бәйрәм көннәрендәге кебек иде. Бөтен халык безнең йөгерү юлына чыккандыр. Бигрәк тә, мәктәпләр тирәсендә зур шатлык сизелә: оркестрлар уйный, әләмнәр балкый, аерым дөмбер кагулар, быргы тавышлары ишетелә.

Стартны без торган җирдән якында гына, шәһәр уртасыннан аккан Сүнҗә елгасы күперен чыгуга, «Минутка» дигән мәйданда бирделәр. 21 чакрым 97,5 метр йөгергәч, без борылып, янә шул мәйданга кайтып җитәргә тиеш. Бу — 42 чакрым 195 метрлы марафон була. Аны мин бүген беренче тапкыр йөгерәчәкмен. Йа, аллам, исән-сау кайтып җитә алырмынмы, борынгы тарихтагы грек солдаты кебек егылып үлмәмме, дигән шомлы уйлар да килә башыма.

Һавага яшел ракета җибәреп старт бирделәр. Барыбыз да «Ура!» кычкырып, дошман ныгытмасына һөҗүм итүчеләр кебек, алга ташландык. Өч йөз йөгерешченең аяк астында җир тетри. Марафон 35 чакрымнан соң башлана диләр. Чыннан да марафоным «утыз биштән» башланды. Утыздан соң аякларымда арыганлык, авырткалау сизелә башлады. «Утыз биштә» көзән җыерырга тотынды. Алга атламакчы булам — балтыр итләре артка тарта. Түздем! Финишка җиттем. Мин — Марафончы! Вакытым — 2 сәгать 37,45 секунд».

Нил Гатинның иң әһәмиятле йөгереше дип, аның Татарстан җиңел атлетикасы тарихында беренче тапкыр уздырылган Казан марафонында җиңүен санарга кирәктер.

Егетнең һәвәскәр мавыгудан башлаган эше аның төп һөнәренә әйләнде. Ул Мәскәү спорт институтында укып икенче диплом алды. Казан авиация институтында физик тәрбия укытучысы булып эшли башлады.

Мораса үзенең марафончы чемпионы белән горурлана. Республика Дәүләт музеенның филиалы булган Колбай-Мораса «Габдулла Кариев музее»нда йөгерешче Нил Гатин турында да авылдашлары махсус бүлек ачкан. — «Анда минем кубоклар, диплом-грамоталарым, шәхси әйберләремне җыеп, өч йөзләп экспонат туплаганнар», — ди Нил Нуруллович. Шөкер, инде җитмеш яшеннән узган Нил Гатин сау-сәламәт. Ял итәр өчен, үзе торган җиргә якын Соцгород бакчасына чыгып йөгерүләрен дәвам итә!

Фотолар авторның шәхси архивыннан.

Камил Мохтаров,
СССРның халыкара класслы спорт мастеры

РЕЗЮМЕ
В воспоминаниях ветерана спорта, мастера спорта СССР международного класса Камиля Мухтарова рассказывается о первом чемпионе Татарстана в марафонском беге Ниле Гатине. На фоне побед спортсмена раскрывается полувековая история бега на длинные и сверхдлинные дистанции. В написании автором был использован дневник Н. Гатина.